Сокланырдай кыйлган гамәле
Шаһит бүген Мәчет манарасы

Марс бүген авылымның
Газиз сөекле баласы
Олы шәхес булган ир лачыны
Хөрмәте ул бүген һәм даны.

Түбән Мактама халкының җирле сөйләш үзенчәлекләреннән берничә мисал:

Юмайлап - төчеләнеп
Алагаем - күп итеп, санаусыз
Җилдерү - кайнатып алу
Ие - иде
Телтәвеч - ?
Эшләнчек - кул белән эшләнгән сәнгати вак әйберләр (мәсәлән, чигү эшләнчекләре)
Тиңелте - кадәр, хәтле
Бөтенәйсе - бөтенесе
Сүләшү - сөйләшү
Үрәнү - өйрәнү
Җырмачлану - җәрәхәтләнү
Коштабак - тирән табак
Инәй - әни
Зур инәй - әтинең я әнинең апасы
Зур әти - әтинең я әнинең абыйсы
Ләкаб - кушамат

Түбән Мактамада наз, сөю, гыйшык хисләрен белдергән сүзләр:

Иркәм, кадерлем, апаем, әнкәсе, әткәсе, бабасы, әбисе, җимеш бөртегем, сары чыпчыгым, оланым, бәбекәем, җаным, газизем, сабыем.

Түбән Мактама халкының үз-үзенә биргән үзенчәлекле сыйфатлары:

Бик тырыш, уңган, горур, үзсүзле, сугышчан, кызу канлы, чая, төртмәле телле, кытыршы, чигенүне белми, чигенсәләрдә урап-урап максатына барып җитәләр...

Фазыл абзый абзарында кызыл бозау бозаулаган.

Юмайлап - төчеләнеп
алагаем - санамыйча, күп итеп
Җилдерү - аз гына кайнатып алу
Исәпле - хәсрәтле. Ил өчен тиле кайгырган, эт тибенгесе
телтәвеч ?
ие - иде
тиңелте - кадәр, хәтле
бөтенәйсе - бөтенесе
сүләшү - сөйләшү
үрәнү - өйрәнү
җырмачлану - җәрәхәтләнү
инәй - әни
зур ~~олы~~ инәй - әтинең я әнинең апасы ?
зур ~~олы~~ әти - әтинең я әнинең олы абыйсы ?
абый - якын иткән үзеңнән олы ир кешегә эндәшү
абзый - хөрмәт итеп үзеңнән олы ир кешегә эндәшү
бабай, әби - әтинең, энинең әти-әнисе
коштабак - тирән табак
түтәй - апа
җизнәй - җизни
[illegible] —

Вәсиләттәй, Хөмәйрәттәй - уменшительно - ласкатетельно (?) эндәшү, ирләргә карата назлы эндәшү юк.
Ләкаб - кушамат
Мәсәлән: Озын Хәйдәр, Төлке Хәлим, Торналар
Жыен тавы - Түбән Мактама белән Габдрахман арасында, Зират тавы, Нәдер тавы - Очлы Тау, Каравыл Тау, Печмән елга, Кыларасы күле, Түгәрәк күл, Инеш, Аркыстө (Арка өсте - басу ?), Аркыстө күле, Морат тавы - Бөгелмәгә барганда, Имән юлы - Зәй әрәмәлегенә барганда, Каен юлы - Бөгелмә белән Элмәт юлына Эби патша хөрмәтенә утыртылган агачлар, яшен суга, авыр сугыш елларында кисеп бетерәләр), Кортүбәк - Кыртүбәк (урман)? - басу, Исмәгыйл кыры - басу, Сарысаз - ?, Каенкул (каенлы култык)
Капкалар - Хөрәсән капкасы, Элмәт очы капкасы, Габдерахман капкасы, басу капкасы - ? Нәдер капка

Шу-ү-ү-ү... тфү, тфү, тфү...

Биби Мөшкелбикә, Биби Дәрманбикә, Биби Эҗәлбикә, Биби Сишәмбебикә, Биби Чәршәмбебикә, Биби Зәмратбикә, Биби Мәхмүдәбикә, Шу-ү-ү-ү... тфү, тфү, тфү...

Фотографии: Виды деревни, наличники на окнах, ворота с изображениями солнца, деревенский житель на фоне своего дома.

Хафизәләм, иркәм

Ак куян дип аткан идем,
Булды тауның катлавы;
Аргы яктан берәү килә,
Хафизәләм иркәм атлавы.
    Хафизәләм, иркәм, ай, аппагым,
    Бигрәк матур калфагың.

Мамык перчатка эчендә
Алтын балдак шәүләсе;
Күзем йомсам, күз алдымда
Хафизәләм, иркәм гәүдәсе.
    Хафизәләм, иркәм, ай, аппагым,
    Бер күрерменме тагын?

Полиграфкомбинат, 000382

Илалетдинов ~~Миңлеәхмәт кызы~~ Миңлегаян дәфтәреннән

Чыгар идем олы юлга, олы юл нур белән тулган,
Элхәмдүлилляаһи шөкер - Мөхәммәт өммәте булган.

Гамәлләрне укыгачтин, бәндәләрнең һушы китәр,
Гөнаһалы бәндәләргә зөбанилар килеп җитәр.

Раббем Алла, Раббем Алла, җаннарымны каты алма,
Җаннарымны каты алсаң, ни җаваплар бирим анда

Иляһым, Син минем Раббем, безнең хәлләр сиңа мәгълүм,
Сигез җәннәт сараеннан куймасана безне мәхрүм.

Чәчәк вакты әле дими, авыр үлем хәле дими,
Җаннарыннан артык булган яры кала моның дими.

Кабер атлы мәхкәм сарай, ишеге юк ачып булмый,
Кабердәге әрвахларның хәлен сорап-белеп булмый.

Ходай йөземне ак кыйлсын каберләрдән кубарганда,
Хисабларым җиңел булсын хозурларына барганда.

И дускаем, димәдемме, үләсеңне белмәдеңме,
Чарасыз тар каберләргә керәсеңне белмәдеңме.

Укыйм микән, җитәр микән, бу хәсрәтем бетәр микән,
Җылый-җылый дога кыйлсам, бу әчләрем бушар микән.